**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.11.2018 Казан шәһәре №596

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия спорт федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләр) республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2007 елның 12 апрелендә кул куелган 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» Федераль законның 13 маддәсе 5 өлеше, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 1 августында кул куелган 663 нче номерлы « Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия спорт федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләр) республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү тәртибен һәм региональ спорт федерациясе статусы барлыгын дәлилли торган дәүләт аккредитациясе турында документ формасын раслау турында» боерыгы нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия иҗтимгый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлә торган административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 26 декабрендә кул куелган 841 нче номерлы «Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгын гамәлдән чыккан дип санарга.
3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
21.11.2018
596 нчы боерыгы белән
РАСЛАНГАН

**Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: региональ иҗтимагый оешма – юридик зат; бөтенроссия спорт федерациясе структура бүлекчәсе (региональ бүлек) (алга таба – Гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: 420107, Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне, 9:00 дан 18:00 кадәр, төшке аш вакыты 12:30 дан 13:30 кадәр.

Гаризалар кабул итү: шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне, 9:00 дан 18:00 кадәр, төшке аш вакыты 12:30 дан 13:30 кадәр.

Җәмәгать транспортында 8, 10, 10а, 30, 35, 35а, 48, 54, 63, 65, 71, 83, 90, 91, 99а нче номерлы автобуслар;

- 7, 17, 19, 20, 21 нче номерлы троллейбуслар белән «Божра» тукталышына, метро белән «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр килергә.

1.3.2. Спорт төрләрен үстерү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә өчен телефоннары: (843) 222-81-46(48).

1.3.3. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайты адресы (алга таба – «Интернет» челтәре): http://minsport.tatarstan.ru, электрон почта адресы: minsport@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Министрлык урнашкан урын һәм аның эш графигы турындагы мәгълүматны түбәндәге юллар белән алырга мөмкин:

1) Гариза бирүчеләр белән эш өчен Министрлык биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша.

Мәгълүмати стендларда Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында(подпунктларында) күрсәтелгән дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minsport.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләре) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итү ысулы аша (телефон буенча яки шәхсән);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать аша (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Салым кодексы;

2007 елның 4 декабреннән 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» Федераль законы (алга таба – 329-ФЗ номерлы Федераль закон) (Российская газета, 2007 ел, 8 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон); (Российская газета, 2010 ел, 30 июль, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә)

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маеннан 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012 ел, № 19, 2338 маддә);

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 1 августыннан 663 нче номерлы ««Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия спорт федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләр) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе тәртибен һәм региональ спорт федерациясе статусы барлыгын дәлилли торган дәүләт аккредитациясе турында документ формасын раслау турында» боерыгы (алга таба – Тәртип) (Российская газета, 2014, 10 сентябрь, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2015 елның 30 мартыннан 276 нчы номерлы «Бөтенроссия һәм аккредитацияләнгән региональ спорт федерацияләре реестрын алып бару һәм әлеге реестрда булган белешмәләрне бирү тәртибен раслау турында» боерыгы (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 18 июнь, бастырып чыгару номеры **0001201506180029**);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июленнән 315 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турында нигезләмә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм республика башкарма хакимияте органнарының

норматив хокукый актлары җыентыгы, 2005, № 30, 0695 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кул куелган 880 нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» (алга таба – ТР МК 880 нче номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 маддә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алган хәлдә)

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 6 июленнән «Региональ иҗтимагый оешмаларга республика спорт федерацияләре статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча комиссия төзү турында» 225 нче номерлы боерыгы белән расланган Региональ иҗтимагый оешмаларга республика спорт федерацияләре статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча комиссия турында нигезләмәсе (Министрлыкның рәсми сайты (http://minsport.tatarstan.ru), «Норматив документлар» бүлеге).

1.5. Спорт төре буенча дәүләт аккредитациясе түбәндәге очракларда игълан ителә:

а) спорт төрләренең бөтенроссия реестрының (алга таба – СТБР) беренче бүлегенә – спортның танылган төрләре (хәрби-гамәли, хезмәт-гамәли, шулай ук гомумироссия дәрәҗәсенә үстерелә торган спорт төрләреннән тыш), СТБР икенче бүлегенә – гомумироссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләре, СТБР өченче бүлегенә – әлеге спорт төре буенча региональ спорт федерациясе булмаганда милли спорт төрләрен үз эченә алган спорт төрләре буенча дәүләт аккредитациясен игълан итү өчен Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә;

б) әлеге спорт төре буенча республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе гамәлдә булу вакыты тәмамланганда;

в) әлеге спорт төре буенча республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу вакыты тәмамлану көненә кадәр 4 айдан да кимрәк вакыт эчендә республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясен игълан итү өчен Министрлыкка мөрәҗәгате очрагында.

1.6. Спортның бер төре буенча Татарстан Республикасы территориясендә Министрлык тарафыннан бары тик бер генә республика спорт федерациясе аккредитацияләнә ала.

1.7. Республика спорт федерацияләренә дәүләт аккредитациясе дүрт елдан да артык вакытка тормышка ашырылмый.

1.8. Гариза бирүче вәкиле – үзенең вәкаләтләре көчендә Гариза бирүче исеменнән яисә законнар белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч язуы нигезендә эш итүче зат ул.

1.9. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең

шулар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 нчы номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәсенең 34 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль үзенә аерым структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау (2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 нче маддәсенең 1 нче пункты) дигәнне аңлата. Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында бирелә.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1 Дәүләт хезмәте атамасы | Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе | 329-ФЗ номерлы Федераль закон; Тәртип |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтә торган башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Спорт Министрлыгы | 329-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсенең 5 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | Региональ иҗтимагый оешмаларга яки бөтенроссия спорт иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе турында Министрлык боерыгы<br>Республика спорт федерациясе статусы Министрлыкның региональ иҗтимагый оешмага яки бөтенроссия иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) тиешле спорт төре буенча дәүләт аккредитациясе һәм аларга республика спорт федерациясе статусы бирү турында боерыгы | Тәртипнең 11, 13 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | басылган көннән алынган дип санала.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып; әгәр Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакыты | Дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерык әлеге регламентның 1.5 пунктында каралган шартлар килеп туган көннән 10 эш көне эчендә чыгарыла.<br>Дәүләт аккредитациясе турында гариза бирү вакыты дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерыкка кул куелган көннән соң 20 эш көненнән кимрәк һәм 40 эш көненнән артыграк була алмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат Гариза бирүчегә әлеге Регламентның 2.9 Пунктында каралган шартлар килеп туган вакыттан биш эш көне эчендә юллана.<br>Региональ иҗтимагый оешмага яки бөтенроссия иҗтимагый федерациясе структура бүлекчәләренә (региональ бүлекләргә) дәүләт аккредитациясе һәм аларга республика спорт федерациясе статусы бирү яисә дәүләт аккредитациясен кире кагу турында карар Министрлыкның дәүләт аккредитациясен игълан итү турында боерыгында билгеләнгән Гариза бирүче тарафыннан документлар бирү вакыты үзган көннән соң 40 эш көненнән дә соңрак булмаган вакыт эчендә кабул ителә.<br>Дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү Министрлык тарафыннан «Интернет» челтәрендә РФ Спорт министрлыгының рәсми сайтында РФ Спорт министрлыгының республика спорт федерациясе турында белешмәләрне гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региональ спорт федерацияләре реестрына (алга таба – Реестр) кертү турында боерыгы урнаштырылган көннән соң 15 эш көне эчендә тормышка ашырыла. | Тәртипнең 3п.<br>Тәртипнең 6п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) яңадан рәсмиләштерү дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) яңадан рәсмиләштерү турында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәгән көннән соң 10 эш көне эчендә тормышка ашырыла.<br><br>Дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү турында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәгән көннән соң 30 эш көне эчендә тормышка ашырыла.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | Тәртипнең 11 п.<br><br>Тәртипнең 10 п.<br>Тәртипнең 17 п.<br><br>Тәртипнең 19 п |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри | 1. Дәүләт аккредитациясен алу өчен:<br>а) региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе турында гариза;<br>б) региональ иҗтимагый оешманың Уставы күчермәләре (бер | 329-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсе 2 |

| | | |
|---|---|---|
| булган хезмәтләр өчен Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада да, аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | күчермә нотариаль тәртиптә расланган булырга тиеш) һәм, региональ иҗтимагый оешма юридик зат булып тормаган очракта, гомумроссия спорт федерациясенең даими эшли торган җитәкче органының региональ иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясе бүлекчәсе булып торуы турында, региональ иҗтимагый оешманың урнашкан урыны һәм җитәкче органнары турында мәгълүматларны күрсәтеп, белдерү кәгазе;<br><br>в) региональ иҗтимагый оешма әгъзалары булып торган затлар исемлеге (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);<br><br>г) региональ иҗтимагый оешма җитәкче органнарының персональ (шәхси) составы турында мәгълүматлар (әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы);<br><br>д) иҗтимагый оешма төзү, аның уставын раслау һәм җитәкче органнар һәм тикшерү-ревизия органын формалаштыру турында оештыру съезды (конференциясе) яки гомуми җыелыш беркетмәсенең;<br>коммерциячел булмаган оешманың дәүләт теркәве турында таныклыгының региональ иҗтимагый оешма раслаган күчермәләре;<br>е) гомумроссия спорт федерациясенең иҗтимагый оешмага – СТБР икенче бүлегенә кертелгән спорт төрләре өчен – гомумроссия дәрәҗәсендә үстерелә торган спорт төрләре һәм СТБР өченче бүлегенә – милли спорт төрләре (әлеге спорт төре буенча гомумроссия спорт федерациясе булганда) дәүләт аккредитациясенә язмача ризалык кәгазе;<br>ж) региональ иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясендә членлыгынраслый торган документ күчермәсе (әлеге спорт төре буенча гомумроссия спорт федерациясе | өлешенең 3,4,5 п., Тәртипнең 7, 8п. |

| | | |
|---|---|---|
| | булганда);<br>з) үсешен региональ иҗтимагый оешма тормышка ашыра торган спорт төре буенча Татарстан Республикасы спорт җыелма командасы составына кертү өчен спортчыларны сайлап алуны тәртипкә сала торган документ проекты;<br>и) спорт төре (төрләре) торышына анализны һәм кимендә дүрт еллык вакыт аралыгына исәпләнгән аны үстерү буенча планлаштырыла торган чараларны үз эченә алган спортның тиешле төрен (төрләрен) үстерү программасы проекты – дәүләт аккредитациясе өчен документларны беренче тапкыр тапшыра торган региональ иҗтимагый оешмалар өчен яки спорт төре (төрләрен) үстерү программасын тормышка ашыруның вакыты узган региональ иҗтимагый оешмалар өчен;<br>узган вакыт аралыгында тормышка ашырылган чараларны исәпкә алып, аның төзәтмәләр проекты белән спорт төрен (төрләрен) үстерү программасы күчермәсе – дәүләт аккредитациясе уздыру вакытына спорт төрен (төрләрен) үстерү программасын тормышка ашыруның вакыты чыкмаган региональ спорт федерацияләре өчен;<br>к) региональ иҗтимагый оешма эшчәнлеген финанслау чыганаклары, уздырылган төп чаралар, Татарстан Республикасы җыелма спорт командасының региональ спорт федерациясе үсешен тормышка ашыра торган спорт төре буенча Россия чемпионатларында һәм беренчелекләрендә чыгыш ясау нәтиҗәләре турында белешмә;<br>л) Гариза бирү көненә кадәр бер ел эчендә региональ иҗтимагый оешма уздырган спорт ярышлары беркетмәләре һәм әлеге пунктта каралган документларның күчермәләре.<br>1 пунктның «б» – «ж» подпунктларында каралган мәгълүмат | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм документлар кәгазьдә ике данәдә, шулай ук бер данәдә электрон формада тапшырыла.<br>2. Дәүләт аккредитациясе турында документ дубликатын бирү өчен:<br>а) дәүләт аккредитациясе турында документ дубликатын бирү турында гариза.<br>3. Дәүләт аккредитациясе турында документны яңадан рәсмиләштерү өчен:<br>а) дәүләт аккредитациясе турында документны яңадан рәсмиләштерү турында гариза;<br>б) устав күчермәсе;<br>в) коммерциячел булмаган оешмага дәүләт теркәве үткәрү турында таныклыклар;<br>г) дәүләт аккредитациясе турында элек бирелгән документ. Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (юлланырга) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе буенча гариза бирүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми кулланылыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырыла (җибәрелә) ала. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган һәм Гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларының тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 1. Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе).<br>2. Дәүләт аккредитациясе турында документ бирү өчен дәүләт пошлинасын түләүне дәлилли торган документ (Федераль Казначылыкның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе).<br>Күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры, мөмкинлек булганда – электрон рәвештә дә алынырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны бирмәве гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып тормый.<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокукы булган документларны алу юллары һәм тәкъдим итү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнә.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсе 6 өлешендә каралган документларны бирү дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәвештә килеп чыга торган мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актлар нигезендә каралмаган очраклардан тыш, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары ведомствосында булган югарыда саналган документларны бирү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул | Тәртипнең 7 пунктының «а» п.п. |

| | | |
|---|---|---|
| | итүдән яисә түбәндәге очраклардан тыш дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тарту вакытында аларның булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар бирү:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны беренчел тапшырганнан соң дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләренең үзгәрүе;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тартканнан соң гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларда хаталар булу;<br>документларның гамәлдә булу вакыты чыккан булуы яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тартканнан соң мәгълүматның үзгәрүе;<br>дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тартканда ялгыш яисә законга каршы гамәленең (гамьсезлегенең) документлар белән дәлилләнгән фактын ачыклау, аның турында гариза бирүчегә язма рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган җитәкчесе имзасы белән язмача белдерү кәгазе тапшырыла, шулай ук килеп чыккан уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү таләп ителә һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган | Килештерү каралмый. | |

| | | |
|---|---|---|
| башкарма хакимият органы тормышка ашыра торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структура бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән исемлектән документлар бирелмәү.<br>2. Әлеге Регламентның 2.4 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасы 2 нче абзацында күрсәтелгән документлар һәм гариза бирү вакытын бозу. | Тәртипнең 9 п. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Әлеге Регламентның 2.5. пункты буенча региональ иҗтимагый оешма тәкъдим иткән документларда дөрес булмаган мәгълүмат булуы.<br>2. Региональ иҗтимагый оешманың 329-ФЗ Федераль законы 13 маддәсенең 8 өлешендәге региональ спорт федерацияләренә куелган таләпләргә туры килмәве.<br>3. Региональ спорт федерациясе тарафыннан дәүләт аккредитациясе юридик көчен туктату өчен сәбәп булып торган бозуларны региональ иҗтимагый оешманың юкка чыгармавы (дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы элегрәк туктатылган региональ иҗтимагый оешманың әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган белешмәләр һәм документлар, гариза бирү очрагында).<br>4. Аккредитация буенча органның спортның шул ук төрен үстерүне тормышка ашыра торган башка региональ иҗтимагый | 329-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсе 8 өлеше, Тәртипнең14, 15 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | оешмага дәүләт аккредитациясе уздыру турында карар кабул итүе (ике яки артыграк иҗтимагый оешмалар тарафыннан бирелгән әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган белешмәләр һәм документларны, гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча).<br>Региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрүне кире кагу очрагында андый оешма, кире кагу өчен сәбәп булып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң, Министрлыкка дәүләт аккредитациясен игълан итү өчен кабат мөрәҗәгать итә ала, ләкин әлеге оешмага дәүләт аккредитациясен кире кагу турында карар кабул иткән көннән соң бер елдан да иртәрәк түгел (әлеге Регламентның 4 подпунктында каралган очрактан тыш). | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәп | Дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү республика спорт федерациясен дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү өчен 5 000 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәннән соң тормышка ашырыла.<br>Дәүләт аккредитациясен дәлилли торган турында документ (таныклык) дубликатын бирү дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү өчен 350 сум күләмендә дәүләт пошлинасы түләгәннән соң тормышка ашырыла.<br>Республика спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) һәм дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документ (таныклык) дубликатын бирү өчен дәүләт пошлинасы түләү өчен реквизитлар: реквизитларны тәгаенләргә<br>ТР буенча ФКИ (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы л/сч 04112001180)<br>ИНН/КПП 1655043416/165501001<br>Отделение-НБ Республики Татарстан г. Казань | Россия Федерациясе Салым кодексының 333.33 маддәсе 1 өлеше 73,77п., Тәртипнең 17, 19 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | р/с 40101810800000010001<br>БИК 049205001<br>КОД ДОХОДА 719.10807340011000.110<br>ОКТМО 92701000 | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр | Зарури һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Аккредитация алуга язмача гариза бирү чират булганда – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президенты-ның 2012 елның 7 маеннан 601 номерлы Указы |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, соравын (запрос) теркәү вакыты | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килгән көнне теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән Россия | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәк булган мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла. | ТР МИ 880 нче номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә, шундый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата таләпләр | Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына комачаулыкларсыз килүе (объектларга комачаулыкларсыз керү һәм аннан чыгу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү урынына килү максатларында объект буенча мөстәкыйль күчеп йөрү мөмкинлеге) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытта вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте алуның дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләрне дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>документларны кабул итү һәм бирү алып барыла торган биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы;<br>башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулый торган киртәләрне узуда инвалидларга ярдәм күрсәтү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә Министрлыкның мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. гаризаларны кабул итү һәм карау вакытын үтәү;<br>2. дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу вакытын үтәү;<br>3. дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан җибәрелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | Административ регламентны бозуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>4. гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара тәэсир итешү саны:<br>гариза биргән вакытта – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гаризаны һәм документларны почта аша яисә электрон рәвештә юллаганда – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара тәэсир итешүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Министрлыкка мөрәҗәгать иткән чакта алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирү) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://minsport.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләр) бердәм порталында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында ала ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.<br>Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру тәртибе турында «Интернет» челтәре аша консультация үткәрү мөмкинлеге бар. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрның) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтә урнашкан эш урыннарында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ процедураларын башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта административ процедураларны сурәтләү һәм эзлеклелеге.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган, консультация бирү;

2) дәүләт аккредитациясе үткәрү турында игълан итү өчен гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе үткәрүне игълан итү турында карар кабул итү;

4) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

5) ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү системасы (ВЭХС) аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларына ия органнар адресына ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм юллау;

6) республика иҗтимагый оешмаларына аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча Комиссия утырышын үткәрү, аккредитация буенча Комиссия утырышын уздыру турында беркетмә төзү;

7) региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында карар кабул итү;

8) Россия Федерациясе Спорт министрлыгына республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында мәгълүмат һәм документларны тәкъдим итү, Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү (юллау);

9) дәүләт аккредитациясе үткәрү турында документның (таныклыкның) дубликатын бирү һәм яңадан рәсмләшерү;

10) техник хаталарны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында тәкъдим ителде.

3.2. Гариза язучыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә, ярдәм күрсәтүне күздә тота.

Бүлек белгече шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен алу тәртибе, документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү өлешендә Гариза бирүчегә ярдәм күрсәтүне күз алдында тоткан консультация үткәрә.

Әлеге подпункт белән билгеләнеп куела торган процедура Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне яисә электрон почта буенча мөрәҗәгать иткән көннән алып өч эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның составы һәм эчтәлеге буенча консультация, Гариза бирүчегә документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрү турында игълан итү буенча гаризаны кабул итү һәм теркәү, Гариза бирүчегә консультация үткәрү.

3.3.1. Гариза бирүченең вәкиле кәгазьдә бастырып шәхсән, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә яисә почта аша алу турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә Министрлыкка тиешле спорт төре буенча региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе уздыру турында игълан тү өчен мөрәҗәгать (алга таба – Мөрәҗәгать) юллый.

3.3.2. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Мөрәҗәгатьне терки һәм башкару өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге подпункт белән билгеләп куела торган процедуралар гариза бирүчедән Мөрәҗәгать килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлү узган Мөрәҗәгать.

3.4. Региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе игълан итү турында карар кабул итү.

3.4.1. Мөрәҗәгать нигезендә Бүлек белгече региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе игълан итү турында боерык проекты әзерли (алга таба – Боерык), биредә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында гариза бирү вакыты билгеләп куела. Ул әлеге Боерыкка кул куелган көннән башлап 20 эш көненнән дә кимрәк һәм 40 эш көненнән артыграк булмаган вакытны үз эченә алырга тиеш.

Боерык проекты килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелә.

Әлеге подпункт белән билгеләнлә торган процедура әлеге Регламентның 3.3.2 подпункты белән билгеләнгән процедуралар тәмамланганнан вакыттан алып ике эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен юлланган Боерык проекты.

3.4.2. Бүлек башлыгы Боерык проектын карый һәм килештерү өчен аларны министр урынбасарына юллый.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы белән килештерелгән Боерык проекты.

3.4.3. Министр урынбасары Боерык проектын килештерә һәм раслау өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.4.2. һәм 3.4.3. подпунктларында билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга кул куярга юлланган Боерык проекты.

3.4.4. Министр Боерыкны имзалый һәм теркәү өчен оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юллый.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәүгә юлланган Боерык.

3.4.5. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Боерыкны терки һәм башкару өчен Бүлеккә кире кайтара.

Әлеге Регламентның 3.4.4. һәм 3.4.5. подпунктларында билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән Боерык.

3.4.6. Бүлек белгече Боерыкны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан ике эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган Боерык.

3.5.13.5. Гариза алу һәм теркәү

Гариза бирүче вәкиле шәхсән кәгазьдә яки почта аша тапшырылу турында хәбәр кәгазле заказлы хат белән, әлеге Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, гаризаны Бүлеккә тапшыра (юллый).

Документларны кабул итүне кире кагу өчен әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән сәбәпләр булмаганда, Бүлек белгече Гариза бирүчегә почта аша тапшырылу турында хәбәр, гариза бирү ысулына бәйле рәвештә, кәгазьле заказлы хат белән яки электрон рәвештәгаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү датасы турында билге белән исемлек күчермәсен юллый һәм Гариза бирүченең гаризасын һәм документларын оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юллый.

Документларны кабул итүне кире кагу өчен әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән сәбәпләр булган очракта, Бүлек белгече Гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында, документларны кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, хәбәр бирә һәм аңа документларны кире кайтара (юллый).

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм Министрлыкның оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлегенә юлланган Боерык һәм документлар, шулай ук Гариза бирүчегә юлланган гариза һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү датасы турында билге белән исемлек күчермәсе яки Гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.5.2. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече гаризаны терки һәм башкару өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көндә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур булган документлар алар карамагында булган органнарга ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (ВЭХС) аша запросларны формалаштыру һәм юллау.

3.6.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша Федераль Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (ЮЗБДР) мәгълүматлар турында запрос юллый.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәү вакытыннан алып бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында запрос.

3.6.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләр белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә законнарда билгеләнгән вакыт эчендә сорала торган документларны (Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне) тәкъдим итәләр.

3.6.3. Бүлек белгече кергән мәгълүматлар нигезендә:

Гариза бирүченең документларын карау мөмкинлеге турында бәяләмә әзерли һәм региональ иҗтимагый оешмаларга аларга региональ спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча Комиссия утырышында карауга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 6 июленнән «Региональ иҗтимагый оешмаларга аларга региональ спорт федерациясе статусын бирү өчен дәүләт аккредитациясе буенча комиссия төзү турында» 225 нче номерлы боерыгы нигезендә эшли торган Комиссиягә (алга таба – Комиссия) юллый;

дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу һәм документларны кире кайтару өчен сәбәпләр булганда, Бүлек белгече министрга (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) имзага дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу һәм документларны кире кайтару турында, шулай ук документларны кире кайтару өчен нигез булып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң гаризаны кабат бирү мөмкинлеге турында хат проекты әзерли.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан соң бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комиссиягә карауга юлланган бәяләмә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу өчен нигезләмәләр булган очракта – министрга (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка) кул куяр өчен юлланган дәүләт хезмәтен күрсәтүне кире кагу һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп документларны кире кайтару, шулай ук документларны кире кайтару өчен нигез буып торган сәбәпләрне юкка чыгарганнан соң яңадан гариза бирү мөмкинлеге турында хат проекты.

3.6.4. Гаризаны яңадан биргән очракта әлеге Регламентның 3.5.1., 3.5.2. подпунктлары белән каралган процедуралар тормышка ашырыла.

3.7. Региональ спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча Комиссия утырышын үткәрү, Комиссия утырышын үткәрү турында беркетмә төзү.

3.7.1. Комиссия Рәисе Комиссия утырышы көнен билгели.

Комиссия сәркатибе Гариза бирүчегә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша Комиссия утырышы көне турында хәбәр итә.

Әлеге Регламентның 3.7.1. подпункты белән билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны тапшыру вакыты тәмамланган көннән алып өч эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комиссия утырышы көнен билгеләү, Гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.7.2. Комиссия утырышы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 2016 елның 6 апрелендә кул куелган «Республика спорт федерациясе статусы бирү өчен региональ иҗтимагый оешмаларга дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча комиссия булдыру турында» 225 нче номерлы боерык белән каралган тәртиптә үткәрелә.

Әлеге Регламентның 3.7.2. подпункты белән билгеләнә торган процедуралар Министрлыкның региональ иҗтимагый оешмаларына дәүләт аккредитациясе уздыру хакында игълан итү турында боерыгында билгеләп куелган Гариза бирүче тарафыннн документлар тапшыру вакыты тәмамланганнан соң 40 эш көненнән дә соңга калмыйча тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комиссия утырышы беркетмәсе.

3.8. Региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе уздыру һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында боерык чыгару яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат.

3.8.1. Бүлек белгече Комиссия утырышында кабул ителгән тәкъдим карары нигезендә:

региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе уздыру һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында боерык проектын (алга таба – Аккредитация үткәрү турында Боерык проекты) яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат проектын (алга таба – Баш тарту турында хат проекты) әзерли;

Аккредитация үткәрү турында Боерык проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге подпунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.7.2. подпунктында билгеләнгән процедуралар тәмамланган вакыттан соң бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен юлланган Аккредитация үткәрү турында Боерык проекты яки Баш тарту турында хат проекты.

3.8.2. Бүлек башлыгы Аккредитация үткәрү турында Боерык проекты яки Баш тарту турында хат проектын карый, аны килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен министр урынбасарына юлланган Аккредитация үткәрү турында Боерык проекты яки Баш тарту турында хат проекты.

3.8.3. Министр урынбасары Аккредитация үткәрү турында Боерык проекты яки Баш тарту турында хат проектын килештерә һәм раслау өчен министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.8.2. һәм 3.8.3. подпунктларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан соң бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: раслау өчен министрга юлланган Аккредитация үткәрү турында Боерык проекты яки Баш тарту турында хат проекты.

3.8.4. Министр карар кабул итә һәм региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе уздыру һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында боерыкка яки региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турындагы хатка кул куя.

Процедура нәтиҗәсе: региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе уздыру һәм аңа республика спорт федерациясе статусы бирү турында кул куелган боерык (алга таба – Боерык) яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында имзаланган хат.

3.8.5. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Боерыкны яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турындагы хатны терки һәм Гариза бирүчегә юллый.

Әлеге Регламентның 3.8.4. һәм 3.8.5. подпунктларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: теркәлгән Боерык яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турындагы хат.

3.8.6. Бүлек белгече:

расланган боерыкны Министрлык сайтында урнаштыра;

гариза бирүчегә дәүләт аккредитациясе үткәрү турында хәбәр итә яки дәүләт аккредитациясе үткәрүдән баш тарту турында хат юллый.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан алып дүрт эш көне дәвамында тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: сайтта урнаштырылган боерык, гариза бирүчегә җиткерелгән хәбәр.

3.9. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына республика спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе үткәрү турындагы мәгълүматны һәм документларны тәкъдим итү.

3.9.1. Бүлек белгече документлар пакетын (республика спорт федерациясе документларын карау турында Министрлык гаризасы, республика спорт федерациясе дәүләт аккредитациясе турында Министрлык боерыгы, республика спорт федерациясе документлары) формалаштыра һәм аны республика спорт федерациясе турында мәгълүматларны гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региональ спорт федерацияләре реестрына (алга таба – Реестр) кертү өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына юллый.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан биш эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Россия Федерациясе Спорт Министрлыгына юлланган документлар.

3.9.2. РФ Спорт министрлыгы карар кабул итә һәм Реестрга региональ спорт федерациясе турында мәгълүматларны кертү турында боерык чыгара яисә

Министрлыкка, сәбәпләрен күрсәтеп, белешмәләрне Реестрга кертүне кире кагу турында хәбәр бирә.

3.9.3. Бүлек белгече «Интернет» челтәрендә РФ Спорт министрлыгы рәсми сайтында РФ Спорт министрлыгының Реестрга республика спорт федерациясе турында мәгълүматларны кертү турында боерыгы урнаштырылганнан соң яисә Министрлыкка белешмәләрне Реестрга кертүне кире кагу турында РФ Спорт министрлыгы хәбәре кергәннән соң дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) ( 1нче кушымта) яки, сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат проектын рәсмиләштерә.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проекты.

3.9.4. Бүлек башлыгы дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы белән килештерелгән дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проекты.

3.9.5. Министр урынбасары дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проектын килештерә һәм министрга имзага юллый.

Процедура нәтиҗәсе: министрга имзага юлланган дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проекты.

3.9.6. Министр дәүләт аккредитациясе турында документка (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проектына кул куя һәм Комиссия секретаренә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат Проекты.

3.9.7. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) дәүләт аккредитациясе турында документлар (таныклыклар) бирү реестрында терки һәм, Гариза бирүче республика спорт федерациясе дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) бирү өчен дәүләт пошлинасы түләгәннән соң, аны Гариза бирүчегә бирә (юллый) яки Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хатны терки һәм гариза бирүчегә юллый.

Әлеге Регламентның 3.9.3. – 3.9.7. подпунктларында билгеләнә торган процедуралар «Интернет» челтәрендә РФ Спорт министрлыгы рәсми сайтында РФ Спорт министрлыгының гомумроссия һәм аккредитацияләнгән спорт федерацияләре реестрына республика спорт федерациясе турында мәгълүматларны кертү турында боерыгы урнаштырылганнан соң 15 эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында Гариза бирүчегә бирелгән (юлланган) хат.

3.10. Дәүләт аккредитациясе турында документның (таныклыкның) дубликатын бирү яки документны яңадан рәсмиләштерү.

3.10.1. Дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) югалткан очракта республика спорт федерациясе бу хакта Министрлыкка хәбәр итә һәм дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документның (таныклыкның) дубликатын бирү турында гариза бирә. Гариза бирүченең вәкиле шәхсән, почта аша алу турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә дәүләт аккредитациясен дәлилли торган документның (таныклыкның) дубликатын бирү турында ирекле формада гариза бирә (юллый).

3.10.2. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) дубликатын әзерли, аны юридик эш секторында раслата һәм аны Гариза бирүчегә җибәрә.

Дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) дубликатын бирү Министрлыкка дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) дубликатын бирү турында гариза кергәннән соң 30 эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә бирелгән (юлланган) дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) дубликаты.

3.10.3. Республика спорт федерациясенең атамасы яки юридик адресы үзгәргән очракта Гариза бирүче 15 эш көне эчендә шәхсән яисә Вәкиле аша яисә почта аша алу турында хәбәр белән заказлы хат рәвешендә, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны, шулай ук элегрәк бирелгән дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) теркәп, дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) яңадан рәсмиләштерү турында гариза (ирекле формада), бирә (юллый).

3.10.4. Дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) яңадан рәсмиләштерү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү, документларның әлеге Регламентның 2.5 пункты 3 подпунктына туры килүен тикшерү, документларның әлеге Регламентның 2.5 пункты 3 подпункты таләпләренә туры килмәгән очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу турында карар кабул иткәндә Гариза бирүчегә хәбәр итү процедуралары, шулай ук, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган мәгълүматларны бирү турында запрос юллау процедурасы әлеге Регламентның 3.5 һәм 3.6 подпунктлары буенча тормышка ашырылалар.

3.10.5. Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк һәм аның карамагында булган ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы кысаларында кергән документлар, дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклык) яңадан рәсмиләштерү турында гариза һәм аңа теркәлгән документлар, шулай ук Министрлыкта булган Гариза бирүчегә дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык) бирү белән бәйле мәгълүматлар нигезендә:

Гариза бирүченең дәүләт аккредитациясе турында Министрлык боерыгына ( алга таба – Министрлык Боерыгы) төзәтмәләр кертү турында карар кабул итә;

Министрлык Боерыгы проектын әзерли яисә Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу һәм, сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кире кайтару (дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу турында карар кабул иткән очракта) турында хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерүгә юллый.

Әлеге подпунктта күрсәтелгән процедуралар гариза теркәү вакытыннан ике эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә юлланган Министрлык Боерыгы проекты яки Гариза бирүчегә кире кагу турында хат проекты.

3.10.6. Бүлек башлыгы Министрлык Боерыгы проектын яки Гариза бирүчегә кире кагу турында хәбәр проектын килештерә һәм килештерү өчен министр урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы килештергән Министрлык Боерыгы проекты яки Гариза бирүчегә кире кагу турында хат проекты.

3.10.7. Министр урынбасары Министрлык Боерыгы проектын яки Гариза бирүчегә кире кагу турында хәбәр проектын килештерә һәм имзага министрга юллый.

Әлеге Регламентның 3.10.6. һәм 3.10.7. подпунктларына билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: министрга имзага юлланган Министрлык Боерыгы проекты яки Гариза бирүчегә кире кагу турында хат проекты.

3.10.8. Министр Министрлык Боерыгына яки Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу турында хатка имзасын куя.

Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече Бүлеккә кире кайтара торган Министрлык Боерыгын һәм гариза бирүчегә юллый торган дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу турында хатны терки.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедуралар документлар имзага кергән көндә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрлык Боерыгы яки Гариза бирүчегә юлланган дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу турында хат.

3.10.9. Бүлек белгече Министрлык боерыгын Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган аккредитацияләнгән федерацияләр исемлегенә үзгәртмәләр кертә.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан ике эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган Министрлык Боерыгы һәм Министрлык сайтында урнаштырылган исемлекккә кертелгән үзгәрешләр.

3.10.10. Бүлек белгече дәүләт аккредитациясе турында яңа документны (таныклыкны) рәсмиләштерә, дәүләт аккредитациясе турында яңа документны (таныклыкны) дәүләт аккредитациясе турында документлар (таныклыклар) бирүне теркәү журналына терки һәм дәүләт аккредитациясе турында яңа документны (таныклыкны) Гариза бирүчегә бирә (җибәрә).

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан ике эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт аккредитациясе турында Гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) яңа документ (таныклык).

3.10.11. Бүлек белгече Россия Федерациясе Спорт министрлыгына региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) яңадан рәсмиләштерү турында мәгълүмат юллый.

Әлеге подпунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан өч эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясе турында документны (таныклыкны) яңадан рәсмиләштерү турында Россия Федерациясе Спорт министрлыгына юлланган мәгълүмат.

3.11. Дәүләт хезмәте КФҮтә, КФҮнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

3.12. Техник хаталарны төзәтү.

3.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта Гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне бирә:

техник хатаны төзәтү турында (ирекле формада) гариза;

техник хата булган дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак Гариза бирүчегә бирелгән дәүләт аккредитациясе турында документ (таныклык).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән яисә почта аша, яисә электрон почта ярдәмендә, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша бирелә.

3.12.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү вакытыннан бер эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга юлланган кабул итеп алынган һәм теркәлгән гариза.

3.12.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатында әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны тормышка ашыра һәм гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә), гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хата булган документның оригиналын алганнан соң, имза куйдырып, төзәтелгән документны бирә яки гариза бирүче адресына почта (электрон почта) аша, техник хата булган документның оригиналын Бүлеккә тапшырганда, документ алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алган вакыттан өч эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (юлланган) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләрне карау, тикшерүләр уздыру, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне, Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамьсезлекләренә) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне тикшерү формалары булып түбәндәге тикшерүләрне үткәрү тора:

эш башкаруны алып баруны;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклауны;

дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәүне.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедураларны үтәүне тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмә (справка) бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләгән гамәлләр эзлеклелеген саклауны агымдагы тикшерү министрның беренче урынбасары тарафыннан тормышка ашырыла.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозган очракларны ачыклаган чакта гаепле затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирү

5.1. Гариза бирүчеләрнең Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар. Министр тарафыннан кабул ителгән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге

очракларда да:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны (запрос) теркәү вакытын бозган очракта;
- дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозганда;
- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган яки тормышка ашырылмаган документлар яки мәгълүматлар таләп иткәндә яисә гамәлләр кылганда ;

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозганда;

- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында аларны таләп итү яки кылу каралмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәл кылуны таләп иткәндә;

- гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүне кире каккан чакта;

- әгәр кире кагу өчен нигезләмәләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире какканда;

- әгәр туктату өчен сәбәпләр федераль законнар, аларга бәйле кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;

- Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозган чагында;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 маддәсенең 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире кагу вакытында аларның булмавы яисә дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат таләп итү.

5.2. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Шикаять почта аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты http://minsport.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/)

аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органга яисә югары органга (ул булганда) кергән шикаятьне карау аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көне дәвамында, дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән язудагы һәм басмадагы хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять белдергән очракта яисә мондый төр төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять язган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында тормышка ашырылырга тиеш.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең атамасы (исеме);

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) белән килешмәгән дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә сурәтләнгән хәлләрне раслый торган документлар күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта аңарга теркәлә торган документлар исемлеге дә куела.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәсе буларак түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда язуда һәм басмада җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчалата чараларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә шикаять канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге Регламентның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача яисә гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап юллана.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип таныган очракта, гариза бирүчегә адресланган җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен

гафу үтенелә һәм алга таба дәүләт хезмәтен алу максатында гариза бирүчегә башкарырга кирәк булган эш-гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп нигезле аңлатма, шулай ук әлеге карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау дәвамында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган барлык материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки
гомумроссия иҗтимагый федерацияләрнең
структур подразделениеләренә (региональ
бүлекчәләренә) аларга республика спорт
федерациясе статусы бирү өчен дәүләт
аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең Административ регламентына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы**

Республика спорт федерациясе статусы барлыгын раслый торган
дәүләт аккредитациясе үткәрү турында
ТАНЫКЛЫК

___________ № __________
(бирү вакыты) (сан белән)

_______________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың тулы атамасы, шул исәптән оештыру-хокукый формасын да кертеп)

_______________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың төп дәүләт теркәү номеры)

_______________________________________________________________
(иҗтимагый оешманың адресы (урнашу урыны))

________________________________________ спорт төре буенча аккредитацияләнде,
(спорт төре атамасы, Спорт төрләренең бөтенроссия реестры нигезендә спорт төре номер-коды)

дәүләт аккредитациясе уздыру турында карар нигезендә ________________________
(документ реквизитлары)

_______________________ дан ______________________ кадәр

(дата) (дата)

республика спорт федерациясе статусы бирелде һәм

_______________________________________________________________
(гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региональ спорт федерацияләре реестры буенча бирелгән номер-код)

номер-коды белән гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региональ спорт федерацияләре реестрына кертелде.

__________________________
(Министр (имза) (инициаллар, фамилия)

М.У.

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия иҗтимагый федерацияләрнең структур подразделениеләренә (региональ бүлекчәләренә) аларга республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 2 нче кушымта

үрнәк

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

20__ елның «___» __________________ кул куелган дәүләт аккредитациясен үткәрү хакында игълан итү турында боерык нигезендә түбәндәге спорт төре буенча:

| СТБР нигезендә спорт төре атамасы | СТБР нигезендә спорт төренең номер-коды | Региональ иҗтимагый оешманың тулы атамасы, оештыру-хокукый формасын да кертеп |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрү турында

**ГАРИЗА**

Региональ спорт федерациясенең юридик адресы

| | |
|---|---|
| Кушымта: | 1. Уставның региональ иҗтимагый оешма тарафыннан расланган күчермәләре (ике нөсхәнең берсе нотариаль рәвештә расланган булырга тиеш): оештыру съезды (конференциясе) яки иҗтимагый оешма төзү, аның уставын раслау һәм җитәкче органнар һәм тикшерү-ревизия органын булдыру турында гомуми җыелыш беркетмәсе, юстиция органында теркәлү турында таныклык, 2 нөсхәдә ___ биттә. |
| | 2. Региональ спорт федерациясенең даими рәвештә эшли торган идарә органы составына керүче затлар исемлеге һәм әлеге идарә органын сайлап кую турында беркетмә күчермәсе 2 нөсхәдә ____ биттә |
| | 3. Региональ спорт федерациясе әгъзалары булып тора торган затлар исемлеге 2 нөсхәдә ____ биттә |
| | 4. Региональ иҗтимагый оешманың гомумроссия спорт федерациясе әгъзасы булып торуын раслый торган документ күчермәсе 1 нөсхәдә ___ биттә.[1] |
| | 5. Гомумроссия спорт федерациясенең региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе үткәрүне язмача килештерүнең (329-ФЗ законының 13 маддәсе 5 өлеше) оригиналы һәм күчермәсе ___ биттә.[2] |
| | 6. Россия Федерациясе субъектының җыелма спорт командасы составына кертү өчен спортчыларны сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмә проекты 1 нөсхәдә ____биттә |
| | 7. Спорт төрен үстерү программасы 1 нөсхәдә _____ биттә. |
| | 8. Региональ иҗтимагый оешма эшчәнлеген финанслау чыганаклары турында белешмә 1 нөсхәдә ___ биттә. |
| | 9. Дәүләт аккредитациясе үткәрү турында гариза бирүгә кадәр узган бер ел эчендә региональ иҗтимагый оешма тарафыннан уздырылганн региональ ярышларның беркетмә күчермәләре 1 нөсхәдә _____ биттә |
| | 10. Гаризаны, шулай ук югарыда күрсәтелгән мәгълүмат һәм документларны үз эченә алган электрон җайланма (CD диск, флэш карта) – 1 данә |

(РИО җитәкчесе вазыйфасы) (имза) (И.А.и. Фамилия)

"______"________________ 20___ел М.У.

[1] – региональ иҗтимагый оешма гомумроссия спорт федерациясе әгъзасы булып торган очракта тәкъдим ителә

[2] – региональ иҗтимагый оешма СТБРның берече яки өченче өлешенә кертелгән спорт төре буенча дәүләт аккредитациясе үткәрү өчен гариза бирә икән, әлеге документ тәкъдим ителми.

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия
иҗтимагый федерацияләрнең структур
подразделениеләренә (региональ бүлекчәләренә)
республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт
аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламентына 3 нче кушымта

___________________________________________________________

(региональ иҗтимагый оешманың, оештыру-хокукый формасын да кертеп, тулы атамасы)

региональ иҗтимагый оешма (РИО) әгъзалары булган затлар [____________] га карата

(тутыру датасы – число, ай, ел)

**ИСЕМЛЕГЕ**

**Физик затлар**

| №№ | Фамилия, исеме, атасының исеме |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| … | |

**Иҗтимагый берләшмәләр – юридик затлар**

| №№ | Иҗтимагый берләшмә – юридик затның, оештыру-хокукый формасын кертеп, тулы атамасы |
|---|---|
| 1 | |
| 2 | |
| 3 | |
| 4 | |
| … | |

______________________________ ______________________________ ______________________________

(РИО җитәкчесе вазыйфасы) (имза) (И.Аи. Фамилия)

"_____"___________20___ел

М.У.

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки
гомумроссия иҗтимагый федерацияләрнең
структур подразделениеләренә (региональ
бүлекчәләренә) республика спорт
федерациясе статусы бирү өчен дәүләт
аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең Административ
регламентына 4 нче кушымта

Региональ иҗтимагый оешма (РИО) җитәкче органнарының персональ составы турында

**МӘГЪЛҮМАТ**

______________________________________________________________

( региональ иҗтимагый оешманың, оештыру-хокукый формасын кертеп, тулы атамасы)

[ ] га карата

(тутыру датасы – көн, ай, ел)

______________________________________________________________

(РИО уставы буенча даими эшли торган җитәкче орган атамасы– идарә, президиум, башкарма комитет яки башкалар)

Җитәкче органның вәкаләтләре вакыты[1]: [ ] (көн) дан [ ] (көн) кадәр

| №№ | Фамилия, Исем, Атасының исеме (тулысынча) | Җитәкче органдагы вазыйфасы | Туу датасы (көн, ай, ел) | Паспорт сериясе, номеры, бирү датасы һәм паспорт биргән орган атамасы | Даими тору урыны адресы[2], телефон номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| … | | | | | |

____________________ ____________ ____________________ "____"________20___ел М.У.

( РСФ җитәкчесе вазыйфасы ) (Имза) (И.Аи. Фамилия)

[1] - соңгы хисап-сайлау конференциясен үткәрү көненән РИО уставы нигезендә РИО даими эшли торган җитәкче органының вәкаләтләре вакыты күрсәтелә.
[2] - паспорт белешмәләре ниезендә тутырыла.

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия
иҗтимагый федерацияләрнең структур
подразделениеләренә (региональ бүлекчәләренә)
республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт
аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламентына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Спорт Министрлыгына

**Гомумроссия спорт федерациясе тарафыннан региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе бирүне килештерү**

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия спорт федерациясе структур бүлекчәләренә (региональ бүлекләренә) аларга региональ спорт федерациясе статусы бирү өчен Дәүләт аккредитациясе үткәрү һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 1 августыннан 663 нче номерлы (Россия юстиция министрлыгында 2014 елның 5 августында 33458 номеры белән теркәлгән) боерыгы белән расланган региональ спорт федерациясе статусын дәлилли торган дәүләт аккредитациясе турында документ формасы тәртибенең 7 пункты «г» подпункты буенча,

________________________________________________________________________

гомумроссия спорт федерациясенең тулы атамасы,

________________________________________________________________________

оештыру-хокукый формасын, ОГРН, Гомумроссия һәм аккредитацияләнгән региональ спорт федерацияләре реестры буенча номер һәм, әгәр документ реквизитларында күрсәтелмәгән булса, почта адресы, телефон, дәүләт аккредитациясенә ризалык бирә ____________________________________________

Региональ иҗтимагый оешманың, оештыру-хокукый формасын, ОГРН, почта адресын, телефон, спорт төре буенча кертеп, тулы атамасы

«______________________________».

СТБР буенча спорт төре атамасы

Әлеге ризалык ел дәвамында аккредитация алу өчен бирелә.

____________________________

документ реквизитларында күрсәтелмәсә, дата


| | | |
|---|---|---|
| __________________________ | ________________ | ____________________ |
| гомумроссия спорт федерациясе җитәкчесе вазыйфасы атамасы | имза, мөһер | инициаллар, фамилия |


________________________


башкаручы Ф.И.Аи., телефон

Региональ иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия
иҗтимагый федерацияләрнең структур
подразделениеләренә (региональ бүлекчәләренә)
республика спорт федерациясе статусы бирү өчен
дәүләт аккредитациясе уткәрү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына
6 нчы кушымта

Региональ иҗтимагый оешмага дәүләт аккредитациясе
һәм республика спорт федерациясе статусы бирү буенча
дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытында гамәлләр эзлеклелегенең
блок-схемасы




Эш башкару бүлеге белгече документларны терки һәм Бүлек белгеченә юллый
Бүлек белгече документлар комплектын һәм бирү вакытын тикшерә (керү көнендә)
Документлар-ның тулы комплекты
юк
Шәхси кабул итү
Документлар кабул итү формасы
Белгеч язма аңлатма белән документларны кире кайтара (бирү көнендә)
Белгеч ВЭХБС буенча запрос кирәклеген билгели
Запрослар кирәк
юк
әйе
Белгеч документларны кабул итүдән баш тарту турында хат проектын әзерли (5 эш көне)
Белгеч документларны тикшерә. Исәпкә алу эшен формалаштыра һәм Комиссиягә юллый
Белгеч мәгълүмат белән тәэмин итүчеләргә запрослар әзерли һәм ВЭХМС буенча юллый
Бүлек башлыгы һәм министр урынбасары хат проектын килештерә (1 эш көне)
Исәпкә алу эше
Җибәрелгән запрослар
Комиссия сәркатебе утырыш вакытын билгели һәм гариза бирүчегә хәбәр итә (1 эш көне)
Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр документлар (белешмәләр) юллый (5 эш көне)
Министр хатка имзасын куя Эш башкару бүлеге белгече хатны һәм документларны гариза бирүчегә юллый (1 эш көне)
Документлар
Гариза бирүчегә утырыш датасы турында хәбәр
Комиссия карар кабул итә (утырыш көнендә)
Беркетмә
Гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар
Белгеч аккредитация турында боерык яки дәүләт аккредитациясен кире кагу турында хат әзерли (3 эш көне)
Кабул ителгән карарга бәйле рәвештә
Аккредитация
Кире кагу
Боерык проекты
Кире кагу турында хат проекты
Бүлек башлыгы һәм Министр урынбасары боерык проектын яки кире кагу турында хат проектын килештерә (1 эш көне)
Килештерелгән боерык проекты
Килештерелгән кире кагу турында хат проекты


Министр
боерык яки кире кагу турындагы
хатны имзалый
(1 эш көне)
Имзаланган боерык
Кире кагу турында
имзаланган хат
Эш башкару бүлеге белгече боерыкны
терки (1 эш көне)
Белгеч боерыкны сайтта урнаштыра
(3 эш көне)
Имзаланган һәм
сайтта
урнаштырылган
боерык
Эш башкару Бүлеге
белгече кире кагу
турындагы хатны терки
һәм гариза бирүчегә
юллый
(1 эш көне)
Белгеч документлар
комплектын әзерли һәм РФ
Спорт министрлыгына юллый
(5 эш көне)
РФ Спорт министрлыгына
юлланган документлар
РФ Спорт министрлыгы карар кабул
итә һәм региональ спорт федерациясе
турында мәгълүматны гомумроссия
һәм аккредитацияләнгән региональ
спорт федерацияләре реестрына кертү
турында боерык чыгара яисә ТР СМна,
сәбәбен күрсәтеп, реестрга
мәгълүматлар кертүне кире кагу
турында хәбәр бирә
РФ Спорт
министрлыгы кабул
иткән карарга бәйле
рәвештә
Бүлек белгече
дәүләт
аккредитациясе
турында документ
(таныклык) проектын
рәсмиләштерә
(12 эш көне)
Бүлек белгече
Дәүләт хезмәте
күрсәтүне кире кагу
турында хат
проектын әзерли
(12 эш көне)
Таныклык проекты
Кире кагу турында
хат проекты
Бүлек башлыгы һәм министр
урынбасары боерык проектын
яки таныклык проектын
килештерә
(1 эш көне)
Бүлек башлыгы һәм министр урынбасары
кире кагу турында хат проектын килештерә
(1 эш көне)
Килештерелгән таныклык
проекты
Килештерелгән кире кагу
турында хат проекты
Министр
таныклыкка имзасын куя
(1 эш көне)
Министр
Кире кагу турында хатка имзасын куя (1 эш көне)
Имзаланган таныклык
Кире кагу турында имзаланган хат

Белгеч таныклыкны бирә (1 эш көне)

*Гариза бирүчегә бирелгән дәүләт аккредитациясе турында таныклык*

Эш башкару Бүлеге белгече хатны терки һәм гариза бирүчегә җибәрә
(1 эш көне)

*Гариза бирүчегә дәүләт аккредитациясен үткәрүне кире кагу турында юлланган*

Региональ иҗтимагый оешмаларга
яки гомумроссия иҗтимагый федерацияләрнең
структур подразделениеләренә (региональ
бүлекчәләренә) республика спорт федерациясе
статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Административ регламентына 7 нче кушымта
(белешмә)

**Региональ иҗтимагый оешмаларга яки гомумроссия иҗтимагый федерацияләрнең структур подразделениеләренә (региональ бүлекчәләренә) республика спорт федерациясе статусы бирү өчен дәүләт аккредитациясе үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы  Спорт министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Леонов Владимир Александрович | 222-81-01(02) | Vladimir.Leonov@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасаы Шәйхетдинов Хәлил Хәмитович | 222-81-09 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Югары казанышлар спортын үстерү бүлеге башлыгы Вафин Раиф Ришадович | 222-81-44 | Raif.Vafin@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфасы, ФИО | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре буенча идарә башлыгы<br>Шакирова Гүзәл Рәисовна | 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |